Җомга,
23 май, 2003 ел

Шәһри Казан
ИЛҺАМИЯТ
İLHAMİӘT


## Балачак чакыруы

Еллар үткән саен эндәшә күк
Еракларидан миңа балачагым,
Онытa күрмә, диеп әйтә кебек
Миңа берчак әле кайтачагын.

Син онытсаң, төшләреңдә тагын
Хәтер булып килер үксез чагың,
Офыклардан аваз сала-сала
Шул мизгелгә тагын кайтачагың.

Искә төшеп үткән гомерләрнең
Алларыңа килеп басачагын,
Чыңлап торган газиз чакларыңа
Сине әле алып кайтачагын.

Нигә икән төннәремә килеп
Үксеп-үксеп чакыра балачагым?..


Хәмит ЛАТЫЙПОВ

***Иманыбыз камил: бүген күпләр, бик күпләр үзе өчен яңа шагыйрь, якты хискә, ихласлыкка сусаган күңелләренең иң садә кылларын тибрәндерүче яңа бер шигырь дөньясы ачар. Ул - Хәмит Латыйпов. Хәер, бу исем сәнгать сөючеләргә инде күптән таныш. Һәр сурәткә тирән фәлсәфи мәгънә иңдерүче рәссам буларак беләләр аны. Дөньякүләм танылган рәссам дисәк тә ярыйдыр. Чөнки аның милли рух белән сугарылган байтак әсәре дөньякүләм абруйлы күргәзмә залларында урын алган, халыкара конкурсларда мәртәбә казанган. Хәмит Латыйповның рәсемнәрендә - шигъри фәлсәфә, ә шигырьләрендә исә -сурәтләр. Күңел халәтләренең сурәте. Юк, болар инде шигырь язуны максат итеп сырланган юллар гына түгел, ә көтмәгәндә, күңелнең күккә ташкан бер мәлендә җан түреннән бербөтен булып тырнап, авырттырып чыккан аваз.***

***Хәмит Латыйпов шигырь дөньясының бер читен ачып, үзенә җан һәм илһам биргән Туймазыда «Җир һәм күк» дигән нәни генә китап нәшер иткән иде инде, аннары шагыйрь иҗаты белән әлек Чаллыда чыгып килгән «Аргамак» журналы укучылары танышты, һәм менә, күренекле рәссам Шәмәрдән бистәсенә килеп төпләнеп, андагы сәнгать мәктәбендә сабыйларны матурлыкны күрергә-аңларга өйрәтеп яшәгән шушы мәлендә, шигырьләрен башкала укучысы игътибарына тәкъдим итә.***

## Өзгәләнү

Чәчләремне сүтә искән җилләр,
Берьялгызым торам җилдә басып.
Кайнар йөрәгемне кемгә бирим,
Кемгә сөйлим йөрәгемне ачып?

Нигә уйлар шулай болганалар
Дулкын-дулкын җилләр искән чакта?
Бәлки әле бәлки тынар иде
Хисләремне суга сипкән чакта.

Тынар иде, тынып сүнәр иде
Хисләремне бәлки җыйган чакта.
Янулардан күңел өзеләме,
Үзем түгел гүя җаным башка.

## Искән җилгә каршы чыгып басыйм

Сарытауда күе камышлар бар,
Камышлары гел дә сарыдан
Күзләремә көзге сагыш булып
Сарылары гүя сарылган.

Сарыларын кая куйыйм икән?
Суга салыр идем, - су тирән
Язмыш юлы адаштырды кайчак,
Сагышларым шуңа күп микән.

Сагышлардан сарыланып кына
Үтте гомер әрнеп җан талды.
Искән җилгә каршы чыгып басыйм
Сагышымны китсен җил алып.

## Киту

*(Көе язылмаган җыр.)*

Урман эчләрендә арба юлы,
Урман шаулавында моң тулы.
Киткән чакта күңелләрем тулды
Күзләремә кайнар яшь тулды.
Урман эчләрендә юлым кала,
Юлларымда озатып кем кала?
Барыр юлым әле алда ерак,
Киләчәкләр кайдан юл ала?
Юлларымда көтеп кем кала?
Үткәннәрдә инде гомер кала,
Еракларда якын дус кала.
Яннарыңа их бер кайтыр идем
Нигә ерак икән ул ара?
Нигә ерак икән ул ара?

## Калган

Үткәннәрдә үксез чагым калган,
Калган инде бәгыръ өзелеп,
Өмет калган шыңшып, хисләр калган
Көзге яңгырлардан түгелеп.

Ал таңнарга ак томаннар аша
Хәтер карап калган үрелеп,
Теләк калган, әйтер сүзләр калган
Үксез елларыма күмелеп.

Яшьлекләрем-сагышларым калган
Хәтер тирәгенә бәйләнеп,
Үткәннәрдән их бер килер идем
Иртәнге төш кебек әйләнеп.

